**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статью 18 Закона Республики Татарстан «О градостроительной деятельности в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 ноября 2018 года

**Статья 1**

Внести в статью 18 Закона Республики Татарстан от 25 декабря 2010 года № 98-ЗРТ «О градостроительной деятельности в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 12 (II часть); 2011, № 10 (I часть); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 11 (I часть); 2015, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 41 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 38 (часть I) следующие изменения:

1) часть 6 после слова «объектов)» дополнить словами «, лесохозяйственного регламента, положения об особо охраняемой природной территории»;

2) часть 7 дополнить словами «, а в случае необходимости перевода земельных участков, на которых планируется размещение линейных объектов, из состава земель лесного фонда в земли иных категорий, в том числе после ввода таких объектов в эксплуатацию, с федеральным органом исполнительной власти, осуществляющим функции по контролю и надзору в области лесных отношений, а также по оказанию государственных услуг и управлению государственным имуществом в области лесных отношений», дополнить предложениями следующего содержания: «Документация по планировке территории, подготовленная применительно к особо охраняемой природной территории, до ее утверждения подлежит согласованию с исполнительным органом государственной власти или органом местного самоуправления, в ведении которых находится соответствующая особо охраняемая природная территория. Предметом согласования является

допустимость размещения объектов капитального строительства в соответствии с требованиями лесного законодательства, законодательства об особо охраняемых природных территориях в границах земель лесного фонда, особо охраняемых природных территорий, а также соответствие планируемого размещения объектов капитального строительства, не являющихся линейными объектами, лесохозяйственному регламенту, положению об особо охраняемой природной территории, утвержденным применительно к территории, в границах которой планируется размещение таких объектов, либо возможность размещения объектов капитального строительства при условии перевода земельных участков из состава земель лесного фонда, земель особо охраняемых территорий и объектов в земли иных категорий, если такой перевод допускается в соответствии с законодательством Российской Федерации. Срок согласования документации по планировке территории не может превышать тридцать дней со дня ее поступления в орган государственной власти или орган местного самоуправления, предусмотренные настоящей частью.»;

3) дополнить частью $17^1$ следующего содержания:

«$17^1$. Документация по планировке территории, предусматривающая размещение объекта капитального строительства в границах придорожной полосы автомобильной дороги, до ее утверждения подлежит согласованию с владельцем автомобильной дороги. Предметом согласования документации по планировке территории являются обеспечение неухудшения видимости на автомобильной дороге и других условий безопасности дорожного движения, сохранение возможности проведения работ по содержанию, ремонту автомобильной дороги и входящих в ее состав дорожных сооружений, а также по реконструкции автомобильной дороги в случае, если такая реконструкция предусмотрена утвержденными документами территориального планирования, документацией по планировке территории.»;

4) дополнить частью $17^2$ следующего содержания:

«$17^2$. В случае, если согласие владельца автомобильной дороги на строительство, реконструкцию в границах придорожной полосы автомобильной дороги объекта капитального строительства, для размещения которого требуется подготовка документации по планировке территории, получено до 4 августа 2018 года, согласование с владельцем автомобильной дороги документации по планировке территории не требуется.»;

5) дополнить частью $17^3$ следующего содержания:

«$17^3$. Разногласия между органами государственной власти, органами местного самоуправления и (или) владельцами автомобильных дорог по вопросам согласования документации по планировке территории разрешаются в порядке, установленном Правительством Российской Федерации.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
30 ноября 2018 года
№ 90-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 өлештә «әзерләүдән тыш)» сүзләреннән соң «, урман хуҗалыгы регламенты, махсус саклanылучы табигать территориясе турындагы нигезләмә» сүзләрен өстәргә;

2) 7 өлештә «органнары» сүзеннән соң «, ә линия объектларын урнаштыру планлаштырыла торган җир кишәрлекләрен урман фонды җирләре составыннан башка категория җирләренә күчерү кирәк булган очракта, шул исәптән мондый объектларны файдалануга керткәннән соң да, федераль башкарма хакимиятнең урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү, шулай ук урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт милке белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы органы» сүзләрен һәм түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Махсус саклanылучы табигать территориясенә карата әзерләнгән территорияне планлаштыру документлары расланганчы, алар үз карамагында тиешле махсус саклanылучы табигать территориясе булган дәүләт хакимияте башкарма органы яисә җирле үзидарә органы белән килештерелергә

тиеш. Килештерү предметы урман законнары, махсус сакланылучы табигать территорияләре турындагы законнар таләпләре нигезендә урман фонды, махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләре чикләрендә капиталь төзелеш объектларын урнаштыруны рөхсәт итүдән, шулай ук линия объектлары булып тормаган капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыруның үз чикләрендә мондый объектларны урнаштыру планлаштырыла торган территориягә карата расланган урман хуҗалыгы регламентына, махсус сакланылучы табигать территориясе хакындагы нигезләмәгә туры килүеннән йә, Россия Федерациясе законнары нигезендә җир кишәрлекләрен урман фонды җирләре, махсус сакланылучы территорияләр һәм объектлар җирләре составыннан башка категория җирләренә күчерү рөхсәт ителсә, мондый күчерү башкарылган очракта капиталь төзелеш объектларын урнаштыру мөмкинлегеннән гыйбарәт. Территорияне планлаштыру документларын килештерү срогы аларның әлеге өлештә каралган дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына кергән көненнән алып утыз көннән дә артык була алмый.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $17^1$ өлеш өстәргә:

«$17^1$. Капиталь төзелеш объектын автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру документлары расланганчы, алар автомобиль юлы хуҗасы белән килештерелергә тиеш. Территорияне планлаштыру документларының килештерү предметы автомобиль юлында күз күреме начар булмавын һәм юл хәрәкәте иминлегенең башка шартларын тәэмин итүдән, автомобиль юлын һәм аның составына керә торган юл корылмаларын тоту, ремонтлау, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләү территориаль планлаштыруның, территорияне планлаштыруның расланган документларында каралган очракта, мондый реконструкцияләү эшләре үткәрү мөмкинлеген саклаудан гыйбарәт.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $17^2$ өлеш өстәргә:

«$17^2$. Капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документларын әзерләү таләп ителгән мондый объектны автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә төзүгә, реконструкцияләүгә автомобиль юлы хуҗасының ризалыгы 2018 елның 4 августына кадәр алынган булса, территорияне планлаштыру документларын автомобиль юлы хуҗасы белән килештерү таләп ителми.»;

5) түбәндәге эчтәлекле $17^3$ өлеш өстәргә:

«$17^3$. Территорияне планлаштыру документларын килештерү мәсьәләләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) автомобиль юллары хуҗалары арасындагы фикер каршылыклары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 90-ТРЗ